Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№6 (136)

23 апрель 2015 ел



Аида Сәйдәш фотосы

Татар телле, Тукайлы апрель ае кульминацион ноктага килеп җитте. Бу көннәрдә Казанда 500 катнашучыны берләштергән татар теле һәм әдәбиятыннан III Халыкара олимпиада, «Мин татарча сөйләшәм!» акциясе шаулый. Читтән карасаң, шәһәребез кайнап торган казанны хәтерләтәдер. Россиянең 22 субъектыннан, 10 чит илдән олимпиадага җыелган яшьләр шушы татар телле мохитне сагынып, яратып килгән. Татар теле һәм әдәбияты буенча III Халыкара олипиаданың йомгаклау этабы КФУ базасында уздырыла. Анда укучылар һәм студентлар олимпиада биремнәрен үти һәм «Минем халкым – туган төбәгем һәм мин» дигән темага презентация тәкъдим итә. Олимпиадада катнашучылар Тукайга багышланган туган тел форумында, «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә, «Студентлар язы-2015» фестивалендә, «Сәләт» яшьләр фонды оештырган түгәрәк өстәлләрдә булдылар. Олимпиаданы ябу һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы 23 апрельдә 14.00 сәгатьтә М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында уза.

## • Вакыйгалар эзеннән

Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2015 нче елның 14 нче апрелендә чыккан 656 нче номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Казан (Идел буе) Федераль университеты ректоры вазифасына **ИЛШАТ РӘФКАТЬ** улы **ГАФУРОВ** билгеләнде.

• • • •

КФУ диварларында стоматология буенча беренче Россиякүләм олимпиада уза. Әлеге чара Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Россиянең атказанган теш табибы **МАРСЕЛЬ МИРГАЗИЗОВ**ның 80 яшьлек юбилее уңаеннан оештырылды. Олимпиадада КФУ, Башкорт дәүләт медицина университеты һәм Пенза дәүләт университетыннан килгән 25 булачак теш табибы көч сынашачак. Олимпиада өч өлештән тора: өй эше, биремнәрне жюри каршында эшләү һәм белемнәрне практикада күрсәтү.

• • • •

Апрель аенда КФУга **ҖӘМИЛ ЧИЧЕК** җитәкчелегендә Төркиянең бөек милли берләшмәсеннән вәкиллек килде. Казан университеты Төркия Республикасы уку йортлары һәм фәнни-белем бирү үзәкләре белән тыгыз мөнәсәбәттә тора. Бүгенге көндә КФУның Төркия фәнни үзәге белән ун рәсми килешүе бар. 2014-2015 нче уку елында КФУда Төркиядән 91 студент белем ала. Казан университеты музеенда уздырылган экскурсиядән соң, барлык кунаклар да КФУның Актлар залына җыелдылар. Биредә Җәмил Чичек Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты студентлары өчен махсус лекция укыды.

• • • •

20 нче апрель көнне **КФУ** җитәкчелеге **HALDOR TOPSOE** компаниясе вәкилләре белән очрашты. Haldor Topsoe – өслекләрнең физик һәм химик сыйфатларын өйрәнүдә һәм катализ өлкәсендә дөньякүләм танылу алган оешмаларның берсе.

Эшлекле сөйләшү барышында хезмәттәшлек юллары билгеләнде. Белем бирү программаларын бергәләп эшләү, фәнни-тикшеренү өлкәсендә эшчәнлек алып бару турында да сүз булды. **ИЛШАТ ГАФУРОВ** Haldor Topsoe, Дания техник университеты һәм КФУ арасында өч яклы килешү төзергә тәкъдим итте. Әлеге идея Haldor Topsoeның Мәскәүдәге генераль директоры **ЙЕНС ПЕРРЕРГОРД** тарафыннан уңай кабул ителде. Шулай ук КФУның Инжиниринг үзәгендә компаниянең махсус классын булдыру турында да килештеләр.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

● Белем баскычлары

# Телевидениенең киләчәге бармы?

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Бүгенге технологияләр һәрберебезне «телевизиончы» итте. Кесәңдә гади гаджетың гына булса да, теләсә кайсы чарадан репортаж ясарга мөмкин. Син монда – үзеңә-үзең хуҗа, оператор да, монтажлаучы да, ут куючы да үзең... Әмма сыйфат өчен бу гына җитәме икән?!





Влад Михневский фотосы

Гаммәви коммуникация бүлегендә студентлар өчен дә, укытучылар өчен дә күптән көтелгән вакыйга! Хәзер студент-журналистлар өчен универ эскәмиясеннән зур телевидение дөньясына юл бер адымга якынаерга мөмкин. Чөнки «Татарстан Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры, Россия телевидение академиясе академигы **Илшат Юныс улы Әминов** үзе җитәклиячәк уку-укыту лабораториясе ачылды.

Әлеге иҗат лабораториясе «Илшат Әминов остаханәсе» дип атала. Журфак инде күптән мондый һөнәрханәләргә, үз эшенең остасы булган шәхесләр белән күрешеп аралашуга, аларның эш, уңышсерләрен өйрәнүгә кытлык кичерә иде. Шуңа да бу проект ике як өчен дә отышлы булыр дигән өмет бар.

«Мондый лабораторияләр университетта беренче карлыгачлар түгел. Әмма гуманитар юнәлештә – ул беренче. Без укыту процессын мөмкин кадәр тормышка якынайтырга тырышабыз. Ачылачак остаханә эшчәнлеге нәтиҗәле булыр, ул нәтиҗәне сезнең үрнәктә дә күрергә насыйп булыр, дигән өметтә калам», – диде студентларга мөрәҗәгатендә КФУ проректоры **Р.Минзарипов**.

«*Әлеге лаборатория – телевидение һәм тележитештерү кафедрасы инициативасы*», – дип сүзен башлады И.Әминов. Остазның бурычы изге – студент-журналистларны олы тормыш юлына практик яктан мөмкин кадәр әзерлекле итеп чыгару. Моның өчен уңай шартлар җитәрлек икәнен билгеләп китте ул. Аларга студентлар яратып практика үтә торган ТНВ холдингы да, университетыбызда эшләп килә торган УНИВЕР-ТВ телеканалы да керә. ТНВ үзе – бүген 60 миллион тамашачысы булган медиахолдинг. Аңа «Болгар радиосы», «ТНВ-Татарстан», «ТНВ Планета» телеканаллары, «ТНВ.ру» сайты керә. «Бүген бары шушы каналда гына телевизион журналистиканың барлык жанрлары һәм төрләре сакланып калды», – дип белдерде ул үз компаниясенең өстенлекләрен санап.

Тәҗрибәле, кыю журналист, зур медиахолдинг директоры буларак, Илшат Әминов исеме республикада гына түгел, Россиядә дә билгеле. Безнең өчен шунысы да кызык, ул телевидениедә үскән шәхес: әле 10 яшьлек малай вакытта ук Ш.Усманов урамында урнашкан телестудиядә «Пионерстан» тапшыруын алып барган. Балалык, яшьлек кызыксынуы аны КДУның журналистика бүлегенә алып килгән, ә аспирантураны инде ул Мәскәүдә тәмамлаган. Аның хезмәт юлы узган гасырның 90 нчы елларында криминаль хроника өлкәсендә башлана. Ә бүгенге «Семь дней» дип аталган авторлык тапшыруы республикада яратып кабул ителә торганнардан санала.

Лаборатория кысаларында беренче лекция телевидение нигезләре һәм үзенчәлекләренә багышланды. Лекция студентларда зур кызыксыну уятты. Алар тарафыннан «Телевидениенең киләчәге бармы соң?» дигән сорау куелуы да бу проблемага битараф түгел икәнлегебезне күрсәтә бит. Дөрес, андый бәхәс кино һәм театр арасында да бик күптәннән барган, соңрак аңа газета һәм телевидение арасындагысы да өстәлгән. Инде хәзер бу бәхәскә телевидение һәм интернет кушылып бара. Әмма телевидениегә ясин чыгарга иртәрәк әле.

Икенчедән, әле күптән түгел генә телевидение оператив мәгълүмат җиткерә торган бердәнбер канал иде. Бүген аның урынын социаль челтәрләр биләп бара. Ләкин бу телевидение югала дигән сүз түгел. Телевидение фикер төрлелеге тудыручы, җәмгыять кәефен булдыручы органга әйләнә бара. Моннан 20 ел элек булган һәм хәзерге телестудияләрнең аермасы җир белән күк аермасына тиң. Бүгенге кадрлар өчен төп проблемаларының берсе технологик процессны белмәү булса, икенчесе – иҗади процессның аксавы. Остаханә шушы җитешсезлекләрдән котылу өстендә эшләргә тиеш тә инде.

Без гаммәви мәгълүмат чаралары функцияләреннән иң беренчесе – мәгълүмати, мәгърифәти, тәрбия һәм иң ахырда гына күңел ачу дип белә идек. Әмма бүген бу система тамырдан үзгәреш кичерә. Иң беренче планга телевидениедә күңел ачу функциясе чыкты. Хәзерге ТВ азрак уйлата, фактлар төрлелеге түгел, фикерләр идеологиясе тудыра икән.

Телевидениенең махсуслашуы да безнең күз алдыбызда. Һәрбер телеканал үз аудиториясен экраннар алдында озаграк тотарга тырыша, моның өчен төрле ысуллар эзли. Илшат Әминов фикеренчә, бүген кеше күләмле мәгълүмати чолганышта яши һәм, шул мәгълүмат диңгезендә батып калмас өчен, таяныр нокта эзли. Дөрес, бүген һәркем «тартмачыгында» тәкъдим ителгән 300 канал арасыннан үзенә ошаганнарын гына сайлап, үз телевидениесен булдырырга сәләтле. Әмма ГМЧның төп бурычы – социаль мохиттә ориентлашырга өйрәтү дә бит.

Сөйләшү ахырында Илшат Юныс улы телевидениене иң яхшы гаммәви мәгълүмат чарасы дип атады. Чөнки ул башкалар яшереп калган хис-кичерешләрне, эмоцияләрне алгы планга чыгара. Тик алга таба аларны кабул итәргә теләүчеләр табылыр микән?

***P.S.** Лекция һәм остаханәләр журналист-студентлар өчен атнага ике тапкыр факультатив нигездә узачак. Ачылышта катнашкан тыңлаучылар санына караганда, алар бик популяр булырга охшаган. Чөнки зур аудитория бүлмәсендә алма төшәрлек урын да юк иде, күп студентлар рәт-рәт тезелеп басып тыңлады. Стандарт укыту курсларыннан аермалы буларак, факультатив дәресләр студентларны телевизион программалар төзү процессына актив җәлеп итүне күздә тота. Уңышлы башлангыч кына булсын диясе кала...*

● Эшлекле сөйләшү

# Дин һәм милләт – үтә нечкә темалар

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Милләтара һәм динара мөнәсәбәтләргә кагылышлы вакыйгаларны яктырту өчен, журналистлар нинди белемгә ия булырга тиеш? 17 нче апрельдә КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе конференц-залында бу сорауларга җавап эзләделәр.

«Медиа өлкәсендә этноконфессиональ мөнәсәбәтләр: университетта журналистлар әзерләү һәм практика» дип аталган **«түгәрәк өстәл»** утырышы республикабызның хакимият органнары һәм ММЧ җитәкчеләрен, иҗтимагый һәм дини берләшмә вәкилләрен җыйды. Биредә КФУның Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты укытучылары һәм студентлары да катнашты.



✦ «Ватаным Татарстан» газетасының «Сәясәт һәм дин» бүлеге мөдире Рәшит Минһаҗ һәм ААҖ «Мәгълүмати системалар» директорлар Советы рәисе Марат Бикмуллин

Роза Ибраһимова фотолары



✦ М.Д.Щелкунов белән Татартан республикасының Иҗтимагый палатасы рәисе А.А.Фомин

Журналистика мәйданында мондый җитди мәсьәләнең баш калкытуы көн кадагында торган, күрәсең. Чараның төп сәбәпчесе Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы рәисе **Анатолий Фомин** икән. Президентыбыз **Рөстәм Миңнеханов** уздырган киңәшмәләрнең берсендә ул, дин, тел, милләт мәсьәләсенең матбугат чараларындагы торышына игътибарны арттырырга кирәк, дигән тәкъдим ясый. Анатолий Алексеевич әйтүенчә, дәүләтебез башлыгыннан әлеге проблемага мондый җитди мөнәсәбәт булыр дип һич көтмәгәннәр. «Чыннан да, – ди ул, – әни һәрвакыт әйтә килә иде: ыгы-зыгылы вакытта кеше белән аның дине, теле һәм милләте турында сүз куертма. Еллар аша аның никадәр хаклы булуына тагын да ныграк инанам. Әлеге мәсьәләне дөрес яктырту өчен белгечләр кирәк».

Белгечләр дигәннән, журналистика кафедрасы мөдире **Светлана Шәйхетдинова** чыгышы «Медиа өлкәсендә этноконфессиональ мөнәсәбәтләр» темасына магистрлык программасын тәкъдим итүгә багышланган иде. Шуны билгеләп китү мөһим: бу – Россия югары уку йортлары арасында беренче тәҗрибә. Светлана Каимовна, дин, милләт турында дөрес мәгълүмат бирү өчен, «өч «Т» формуласын истә тотарга кирәклеген искәртте: язмаларында этноконфессиональ мөнәсәбәтләрне яктырткан журналистта Технологик белем, Талант һәм Толерантлык сыйфатлары булырга тиеш.

«Өч «Т» формуласына бер «К» өстәргә кирәк», – дип сүзен башлады Халыклар дуслыгы йорты директоры **Ирек Шәрипов**. Ул безнең чорның төп проблемасы – компетентлыкны күз уңында тота икән: «Этномәдәният, дин турында билгеле дәрәҗәдә белеме һәм тәҗрибәсе булган кешенең генә сүзе абруйлы һәм тәэсирле була ала».

Эшлекле сөйләшүдә дин белгечләренең дә фикере исәпкә алыну бик дөрес иде. Бу уңайдан дин белеме кафедрасы доценты **Ярослав Бухараев** чыгышы кызыклы тоелды. Аның фикеренчә, бу мәсьәләнең дөрес чишелеше ике төрле генә булырга мөмкин: я журналистларга – дин белемен, я дин белгечләренә журналистика серләрен төшендерергә кирәк.

Милләтара мөнәсәбәтләр, дин һәм иман темасы матбугатта әле дә бик четерекле мәсьәлә булып кала. Журналистика кафедрасы доценты **Айрат Бик-Булатов** «Этник мәгълүматның җәнҗал чыгару ихтималы» дип исемләнгән нотыгында дин, тел турында махсус ялган һәм хаталы мәгълүмат бирүләргә ММЧда инде басылып чыккан мәкаләләрдән мисаллар китерде. Чыннан да, вакыйганың мәгънәсенә ишарәләмәгәндә, кешенең милләте, дине турында искәртү бик урынсыз һәм дорфа яңгырый. Журналист, үзе дә белер-белмәс, милли, дини низаг туугa сәбәп барлыкка китерә.

Һәр катнашучы «түгәрәк өстәл» эшчәнлегенең нәтиҗәсе эзсез югалмасын иде, дигән фикерне алга сөрде. Дүртенче хакимият булып торучы вакытлы матбугат чаралары сүзе һәр милләтнең, һәр конфессиянең йөзен билгели бит. Күп милләтле, күп динле Татарстан өчен бу эшнең дөрес һәм оста башкарылуы бик мөһим.

**Бөек җиңүгә - 70 ел!**

Солдат хатлары – беренче карауга бик тә гади, әмма күңелнең түреннән чыккан, йөрәк җылысы белән җылытылган эчкерсез сүзләр. Тирән мәгънәле бу сүзләрдә солдатның бөтен эчке дөньясы, аның тормышка, сугышка мөнәсәбәте, киләчәккә якты өметләре чагыла.



**Кызыклы факт:**
**Махсус өйрәтелгән Джульбарс кушаматлы эт сугышта 7468 мина һәм 150 снаряд таба. Мәскәүдә уздырылган Җиңү парадына берничә көн кала, ул яралана. Сталин этне үзенең шиненә төреп, Кызыл мәйдан буенча алып барырга куша.**



# «Байрагыма каным белән язган Антым чакыра алга барырга»

Бу санда сезнең игътибарга, үз теләге белән сугышка китеп, гади бер солдаттан рота командиры дәрәҗәсенә күтәрелгән КФУ профессоры, фәлсәфәче **Мансур Ибраһим улы Абдрахмановның** хәрәкәттәге армиядән тормыш иптәше Зәйнәпкә, кызы Идиягә язган хатларын тәкъдим итәбез.

Мансур Абдрахманов, сугышта каты яраланып, җиңүче булып кайта. Аның һәрвакыт алга омтылучан йөрәге биредә дә көрәшүдән туктамый. Ул гыйльми эшчәнлек белән шөгыльләнә башлый. Казан университетында аспирантураны уңышлы тәмамлап, фәннәр кандидаты, аннары фәлсәфә фәннәре докторы, профессор була. Университетыбызда философия кафедрасы мөдире, ун елдан артык фәнни эшләр буенча проректор булып эшли.

*Алабуга. 1.09.1941*

*...Минем тормыш һаман шулай бара. Көнбатыш фронт янына Иран килеп кушылды. Әле без курсларны бетергәнче, тагын яңа фронтлар барлыкка килүе ихтимал. Ә монда ятасы килми генә, Зәйнәп. Син алай дигәнгә ачуланасың. Дөресе шулай. Безнең көрәшү һәм бергә булу көннәре немец фашизмын бетерү белән бәйле. Ул көннәр минем Фин фронтыннан кайткан чактагыча булырлар...*

*Фронт хәбәрләре әлегә яхшылардан түгел. Алар әле тагын берникадәр начарланыр. Ләкин шуннан соң туктап кискен борылышка күчәр. Безнең кешеләр саклана, авиация өстенлек итә. Өстәвенә, кыш көннәре җитә. Җиңүнең безнең якта булуында бернинди шик булырга мөмкин түгел. Дөрес, хәл авыр, кан күп түгелә.*

*Ләкин ничек кенә булмасын, сүз фашизмны бөтенләйгә юк итү һәм аны моннан соң телгә алырга оят әшәке бер сүз итеп калдыру турында бара.*

*Нинди хәбәрләр булса да, нинди авырлыклар булса да, безнең җиңәчәгебезгә ышаныч белән кара.*

*Фронт. 17.04.1943*

*...Без – фронтта. Бу хатны командный пункт окобыннан язам. Теге якта – дошман позицияләре. Әле генә безнең самолетлар иртәнге «күчтәнәчләр»не өләшеп кайттылар. «Катюшалар» да бик яхшы эшли. Гомумән, бүгенге фронт музыкасы күңелгә ягымлы. Ротамда хәзергә барысы да исән-саулар.*

*1943 нче елның Май бәйрәмен сугыш кырында каршыларга туры килә инде.*

*Матур көннәр җитәләр. Табигатьнең матурлыгы безгә тыныч тормышны, Чәтрән (Аксубай районы, Яңа Ибрай авылының икенче исеме) урманнарын, сабан туйларын искә төшерә.*

*Тик фашист этләре генә табигатьнең матурлыгына сокланырга, рәхәтләнеп иркен сулыш алырга мөмкинлек бирмиләр. Ләкин тиздән «безнең урамда да бәйрәм булыр!»*



*Воронеж. 15.08.1943*

*Бәгырьләрем Зәйнәп һәм Идия!*

*Мин инде 14 көн бер госпитальдән икенчесенә күчеп йөрим. Хәзер Воронежга килеп җиттем. Моннан кая җибәрерләр. Үзем ничек тә Казанга җибәрүләрен сорыйм.*

*Минем хәл хәзергә зарланырлык түгел. Хатның ямьсез язылган булуына карама – яткан килеш язганга шулай ул. Утырып язарга исә гипстагы аяк ирек бирми. Авырту дәрәҗәсенә һәм врачларның әйтүенә караганда, яралар тиз төзәлергә тиеш.*

**Туган тел сагында**



# «IT IS Tuqay» - бүгенге көн проекты

**Айгөл АБДРАХМАНОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Соңгы берничә елда бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышланган чаралар саны бермә-бер артты. Ләкин яшьләр моның белән генә канәгатьләнми. Ә КФУ студентлары, гомумән, яңадан-яңа проектлар тәкъдим итү һәм аларны тормышка ашыру белән шөгыльләнәләр.

Шундый проектларның берсе – «IT IS Tuqay» флешмобы. КФУның ИТИС югары мәктәбе студентлары – әлеге эшне башлап җибәрүчеләр.

Чара интернет челтәрләрендә Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасын таратуга юнәлтелгән. Оештыручыларны бу адымга Тукай иҗатын бөтен дөньяга таныту теләге этәргән. КФУның рәсми сайтында флешмобта катнашырга теләгән һәркемгә «Шүрәле»дән өзек тәкъдим ителә. Өзекне сәнгатьле итеп башкарып, видеоязмага төшерергә һәм махсус хештеглар белән Инстаграм челтәренә кертергә кирәк.

Оештыру төркеме билгеләвенчә, Тукай иҗатына битараф булмаучылардан берничә дистә видеоязма килгән инде. Шунысы мөһим: «IT IS Tuqay» флешмобы белән кызыксынучылар КФУ студентлары гына түгел, кече яшьтәге мәктәп укучылары, ТРК «*Казань*» *хезмәткәрләре, Г.Камал исемендәге Татар академия театры артистлары да икән. «Проектның территория киңлекләре дә Казан белән генә чикләнми*», - ди оештыру төркеме җитәкчесе **Диана Агапова**. «Шүрәле» поэмасы Мәскәү һәм Франциянең башкаласы Парижда да яңгыраган.

КФУның Япониядән килгән студенты **Хисиямо Ютоның** да флешмобта катнашуы Тукай иҗатын белергә теләүчеләрнең географиясе киң икәнен раслый.

Флешмоб 26 нчы апрельгә кадәр дәвам итәчәк. Ә бөек шагыйребезнең туган көнендә ИТИС югары мәктәбе студентлары иң яхшы чыгышларны берләштергән кыска метражлы фильм тәкъдим итәчәк.

2015 нче елда Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар: шагыйрә Клара Булатова, язучы Камил Кәримов, рәссам Ирина Колмогорцева, кинорежиссер Илдар Матуров, дин белгече Харис Салихов, М.Җәлил ис. Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының «Алтын Урда» спектаклен куйган иҗат коллективы, Рафис Корбан һәм Ләбиб Лерон. Алар арасында Казан университетын тәмамлаучылар да бар. Уңышлар телибез!

# Tatar dozor - 2015

**Эльвира ГАЙНЕТДИНОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

«Мин татарча сөйләшәм, киләчәкне үзгәртәм». Менә шушы девиз белән янып яши бүгенге татар яшьләре.

Аларның төп максаты: Бөтендөнья татар яшьләрен берләштерү, елдан-ел кулланылышы кими барган татар телен үстерү. Шул уңайдан Татарстанда төрле чаралар үткәрелеп тора. Алар арасында иң зур масштаблысы **«Мин татарча сөйләшәм»** акциясе.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышлап үткәрелә торган әлеге чарага әзерлек инде күптән башланып китте. Шуның берсе – 19 апрель көнне үткәрелгән **«Татар дозор 2015» квест-уеннары**. «Иске Казан» префектурасы ярдәме белән бу чара быел инде 7 нче тапкыр үткәрелә.

Квестның төп максаты – республиканың икетеллелек канунын куллануны гамәлгә ашыру һәм шәһәрдә татар теленең кулланылышын тикшерү.

«Татар дозор» квест уеннары ике турдан торды. Икенче турга эләгү өчен, катнашучылар түбәндәге шартларны үтәргә тиеш иде:

1. 7-10 кешедән торган команда туплап, исемләгеен төзү.

2. Кыска һәм кызыклы видео төшерү. Тема: **«Мин татарча сөйләшәм!»** акциясен 10 яшьлек юбилее белән котлау һәм 26 апрель көнне 15:00 сәгатьтә Бауман урамындагы «сәгать» янында узачак концертка чакыру. Шушы видеоны ***Instagram*** һәм ***vk.com*** социаль челтәрләренә ***#tatardozor*** тегы куеп урнаштыру. Кемендә 100 лайк һәм күп санда репост җыю.

3. Кул эшләнмәләре. «Мин татарча сөйләшәм!» логотибын яки, тематикасына туры китереп, кулдан сувенир ясау.

4. Төрле ширкәтләрнең (кибет, почта, сәүдә үзәкләре һ.б. оешмалар) хаталы яки татарчасы бөтенләй язылмаган 20 элмә тактасын фотога төшереп, шулай ук I***nstagram*** һәм ***vk.com*** социаль челтәрләренә ***#tatardozor*** һәм ***#татархатасыз*** тегы куеп урнаштыру. Кемендә 100 like һәм күп санда репост җыю таләп ителә.

5. Мини социаль эксперимент форматында видеоролик. Темасы: «Сездә татарча сөйләшәләрме?». Әлеге видеоны ***#татсынау***, ***#tatardozor*** һәм ***#татархатасыз*** тегы белән ***vk.com*** челтәренә урнаштыру.

«Татар дозор» үз чикләрен елдан-ел киңәйтә, катнашырга теләк белдерүчеләр саны арткаac-арта бара.

«*Ике ел эчендә катнашучылар саны күзгә күренеп артты. Быел аларның саны хәтта 100 дән артып китте. Үзенчәлеге шунда: хәзер Татарстанның төрле район һәм шәһәрләреннән дә командалар катнаша*», – ди Бөтендөнья татар яшьләр форумы рәисе **Тәбрис Яруллин**.

«Татар дозор 2015» уенында барысы 14 команда үзара көч сынашты. Алар Казан шәһәренең тарихи урыннарына багышланган төрле иҗади биремнәр башкарды. Биремнәр үз эченә флэшмоб, шәһәрнең тарихына кагылышлы сораулар һәм табышмакларны алган. Пунктлар бер-берсеннән шактый ерак урнашкан. Мәсәлән, ноктаның берсе Г. Камал театры булса, икенчесе – Ирек мәйданы. Бу, беренче чиратта, башкаланың тарихи урыннарын белүне тикшерү максаты белән эшләнгән. Ләкин энергияләре ташып торган катнашучылар өчен үтә алмаслык киртәләр булмады.

Быелгы квест-уенның үзенчәлеге – бер пунктан икенчесенә командаларны Г.Тукай, Х. Насретдин кебек билгеле шәхесләр каршы алды. Алардан тыш, иң мавыктыргычы, катнашучыларның төрле кафеларга, мәсәлән, яшьләр арасында популяр саналган KFC, шулай ук, сәүдә нокталарына кереп, хезмәткәрләр белән татар телендә аралашулары, телнең кулланылу дәрәҗәләрен тикшерү булды.

Нәтиҗәдә, соңгыноктага беренче булып «Кызлар иле» командасы килеп җитте, аннары «Кәләпүш» һәм «Милләттәшләр». Нәтиҗәләр чыгару һәм катнашучыларны бүләкләү 26 апрельдә Бауман урамында, **«Мин татарча сөйләшәм»** акциясендә узачак. Беренче урын алган командага һәм аның җитәкчесенә «Билайн» ширкәтеннән телефоннар һәм икенче, өченче урыннарга ТР Мәгариф һәм фән министрлыгыннан кыйммәтле бүләкләр каралган.

• Табигать сагында

# «Сәламәт тормыш өчен – сәламәт туфрак»



**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Кичә, ягъни 22 нче апрель көнне, илебез Халыкара Җир-Ана көнен билгеләп үтте. Әлеге дата быел аеруча зур игътибарга лаек, чөнки 2015 ел БМО Генераль Ассамблеясе тарафыннан туфракны саклауга, дөрес һәм максатчан куллануга юнәлтелгән Халыкара туфрак елы дип игълан ителде.

Узган гасырның 70нче елларында АКШда кабул ителгән Халыкара Җир-Ана көне Россиядә 1992нче елдан гына бәйрәм ителә башлый. Зур танылу алмаган әлеге дата турында күбебез белмәсәк тә, бу бәйрәмгә битараф булмаганнар да аз түгел. «Сәламәт тормыш өчен – сәламәт туфрак» шул ел девизына туры килә торган эшчәнлек алып баручы Экология һәм табигый байлыклардан файдалану институтының туфракны өйрәнү кафедрасы вәкилләре нәкъ менә шундыйлардан!

Планетабызның аерылгысыз бер компоненты булган туфракны саклау бүгенге цивилизациянең иң актуаль проблемалары исәбенә керә. Туфракны өйрәнү кафедрасы мөдире **Б.Р. Григорьян** сүзләре буенча, әлеге проблеманы хәл итү өчен туфракның табигать яшәешендәге, җәмгыятьнең тотрыклы үсешендәге ролен һәм функцияләрен аңлау мөһим. Туфрак – Татарстанның стратегик байлыгы, экосистемалар нигезе, биосфераның үзәк буыны, экологик бәйләнешләрне бербөтен итеп туплый торган планетар төен ул. Туфракны саклау буенча эш алып барылмаса, «әйләнә-тирә мохитне саклау» төшенчәсе үз әһәмиятен югалта.

Башка илләрдән аермалы буларак, Россия – искиткеч зур мәйданга, туфрак байлыгына ия булган ил. Өстәвенә, туфракны өйрәнүнең фән буларак формалашуы да нәкъ менә Россиядә! Урманнарга, сулыкларга, туфракка салынган зыян төзәтеп булмаслык казаларга китерергә мөмкин икәнне аңлап, соңгы елларда халык үз гамәлләренә игътибарлырак була башласа да, алда күрсәтелгән проблемаларга бүгенге көндә дә җитәр-җитмәс кенә игътибар бирелүе аяныч. Шуңа да карамастан, әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе актуальлеген югалтмый.

Университетыбызда да бу өлкәдә зур эш алып барыла. Борис Рубенович кафедра хезмәткәрләре, студентлар тарафыннан туфрак һәм әйләнә-тирә мохитне саклауның төрле аспектларын өйрәнү буенча җитдиэзләнү-тикшеренү эшләре алып барылуын ассызыклады. Мәсәлән, яткын җирләрне үзләштерү, өйрәнү, туфракны чистарту һәм аның сыйфатын яхшырту өчен кулланыла торган биочарны (агачны махсус ысул белән яндырып табылган күмер) дөрес файдалану проблемаларын тикшерү эшләре алып барыла. Кафедра ТР Фәннәр Академиясенең Экология проблемалары һәм җир асты байлыкларыннан файдалану институты белән дә актив хезмәттәшлек итә.

Аяк астыбыздагы зур байлык турында безгә дә уйланырга вакыт!

• Дөнья үзебезнеке

# Подиумда – татар модасы



Әйләнә-тирәгездә татар бизәкләре төшерелгән киемле яшьләрне күрсәгез, аптырамагыз: милли мода яңарыш кичерә.



«ТАТАРЧА CASUAL» заманча милли кием проектының максаты – милли мәдәниятебезне яңарту, бәя, сыйфат һәм дизайн ягыннан дөньякүләм брендлар белән көрәшә алырлык популяр татар киеме җитештерү.

«ТАТАРЧА CASUAL» дизайнеры **Мира Рәхмәт**:

«Татар мәдәнияте белән рухлану, хозурлану, аңа мәхәббәт – һәрчак минем белән, һәм бу хисләремне башкалар белән бүлешәсем килә. Милләтемнең мәдәни мирасын аңлау һәм аның белән илһамлану мине үз проектымны булдыруга этәрде: бүген бу идея тормышка аша. Проектыбыз һәр милләт вәкиленә хуш килсен иде. Берәүләрне декоратив бизәлеш әсир итсә, икенчеләр безнең киемнәрнең уңайлы һәм заманча булуын ошатыр.»

Бу проект турында тулырак мәгълүматны газетабызның киләсе саннарында таба алачаксыз.

• Сораштыру

# Син Ленинны беләсеңме?

**Алия КӘЛИМУЛЛИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Урамда яз, димәк, тиздән барлык укучыларны, студентларны, эшчеләрне шимбә өмәсенә дәшәчәкләр. Кемдер бу эшкә уфтанып барса да, тирә-юньне ямьләндерү, чистарту кирәк эш бит. Балачактан ук «Кем уйлап тапкан инде шушы өмәне?» дип уфтандык. Кем булсын инде? Аткалы Ленин бабабыз. Эшләргә дә, укырга да ул өндәгән бит!



«Укырга, укырга һәм укырга!» кебек лозунгларны безгә киңәш сыйфатында юкка гына калдырмагандыр. Күрәсең, яшьләргә дөрес тәрбия бирергә теләгән ул. Уку дигәннән, Казан федераль университеты каршында Ленин һәйкәле дә юкка тормый ич. Кайчандыр университет бусагасыннан безнең кебек ул да атлап кергән. Тарихка күз салыйк...

1887 нче елда Володя Ульянов, алтын медаль белән мәктәпне тәмамлагач, югары уку йортына керергә әзерләнә. Тик аның Мәскәү университеты турында хыяллану мөмкинлеге дә булмый. Чөнки аның абыйсын патшаны үтермәкче булган өчен кулга алалар һәм җәзалап үтерәләр. Шунлыктан Володя Казан университетына юл тота. Ульяновлар гаиләсе Казанны бик яхшы белгән: Ленинның әнисе – Мария Александровна яшьлеген Казанда үткәргән, Казан университетын заманында Владимирның әтисе Илья Николаевич тәмамлаган булган. Монда Ульяновлар гаиләсенең туганнары – Веретенниковлар яши. 1887 елның 13 нче августында Владимир Ульяновны Казан университетына беренче курска кабул итәләр. Тик монда уку дәвере озак булмый. Университетта патша режимына каршы үткәрелгән беренче күтәрелештә катнашу аны революция юлына этәрә. Актив, үтә акыллы, революцион карашлы егетне 18 яше дә тулмаган килеш кулга алалар. Владимир Ульяновны Кокушкино авылына сөргенгә җибәрәләр. Ленинның Казанда уку дәвере нибары бер семестр гына була. Нәтиҗәдә, ул революциянең гениаль юлбашчысына әйләнә, гомере буе царизм һәм капитализмга каршы көрәшеп, социализмга өнди.

Тарих китапларында Ленин исеме бик еш очраса да, соңгы елларда әлеге шәхеснең кем икәнен, хәтта аның Мәскәү мавзолеенда ятуын белүчеләр саны кими бара. Студентлар арасында университетыбыз каршында ни өчен Ленин һәйкәле торуын белмәүчеләр дә бар. Менә нәкъ аларга өч баналь (ә кемгәдер бер дә баналь булмаган!) сорау бирергә булдык: 1) Кем ул Ленин? 2) Ленин безнең Казан федераль университеты белән ничек бәйле? 3) Ленинның туган көне кайчан һәм нәрсә ул «Ленин өмәсе»?

Респондентларның җавапларын укып, нәтиҗәсен үзегез ясагыз...

**АЙЗӘРӘ ГИМАЕВА,**
**Математика һәм механика институты:**

Ленинны белмәгән кеше юктыр инде. Аткалы революционерыбыз бит. Казанда укуы да мәгълүм факт. Беренче өмә 1919 елның 22 нче апрелендә булган. Барлык эшчеләр дә Кремль территориясен чистарткан. Хәтта Ленинның дуслары белән бүрәнә ташуын сурәтләгән фото да бар. Кайдадыр күргән идем. Мондый җәмгыяти эшләр тарихка «Ленин субботнигы» дип кереп калган. Ел саен шәһәрләрне, авылларны кышкы пычрактан чистарту традициясе бүгенгә кадәр сакланып килә. Моның өчен Ленинга рәхмәт!

**ЛИЛИЯ ГАЛИМОВА,**
**Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты:**

Ленин – революционерлар юлбашчысы. Безнең Казан университетында укыган. Әмма революцион карашлы булганга һәм студентларны революциягә өндәгәнгә, аны уку йортыннан куалар. Тууы, ялгышмасам, 1870 елның 22 нче апреле. Ленин өмәләрендә да булганым бар, тик ник Ленинныкы икәнен генә белмим... Әмма ул аларны хуплаган. Үзе дә катнашкан, хәтта бүрәнәләр дә ташыган! Әле «субботник» сүзен дә Ленин үзе уйлап чыгарган бугай...

**ФӘНЗИЛӘ МОСТАФИНА,**
**Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты:**

Ленин – большевикларның юлбашчысы, димәк, 1917-1924 елларда Россия белән идарә иткән кеше. Заманында Казан университетында укып маташкан. Тик, революцион эшчәнлеге өчен, уку йортыннан куып чыгарганнар. 22 нче апрельдә туган көне, шул көнне, гадәт буенча, бөтен илдә өмәләр оештырыла. Минем дә чыкканым бар.

**АЛИНӘ ГАЛИМУЛЛИНА,**
**Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты:**

Ленин – революционер. Университетыбыз каршында аның һәйкәле тора. Ялгышмасам, туган көне апрельдә. Әни «Ленин белән бер көндә тудым» дип гел шаярта иде. Өмә – өмә инде ул. Кемнеке булуы барыбер түгелмени?! Иң мөһиме – җыештыру, чистарту.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: И.Вәлиев, Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.